ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраль 2019ел. № 979

Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирү буенча административ регламентны раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 27 маддәсе, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 41 маддәсендәге 9 бүлекнең 12 пункты, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 17 апрелендәге 30/18 нче карары һәм Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирү буенча административ регламентны (алга таба – административ регламент) кушымтада каралганча яңа редакциядә расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирү буенча административ регламентны раслау турында» 2014 елның 28 маендагы 3100 нче карары;

2) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның 2014 елның 28 маендагы 3100 нче карары белән расланган территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирү буенча административ регламентка үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 29 июнендәге 3348 нче карары.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып

чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның районнар хакимияте Башлыклары И.Н. Галимовка, А.И. Кисловка, Р.М. Усманова йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.А. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 25 февралендәге
979 нчы карарына
кушымта

Территориаль иҗтимагый үзидарә
рәисенә таныклык бирү буенча
административ регламент

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирү буенча административ регламент (алга таба – административ регламент) территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар булып физик затлар тора.

3. Муниципаль хезмәт районнар хакимияте йөзендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

4. Шәһәрнең районнар хакимиятләре түбәндәге адреслар буенча урнашкан:

Комсомол районы – ГЭС поселогы, 8/7 йорт, 6 кабинет.

Үзәк районы – Яңа шәһәр, 3/08 йорт, 101 кабинет.

Автозавод районы – Яңа шәһәр, 49/09 йорт, 215 кабинет.

Шәһәрнең районнар хакимиятләренең эш графигы:

дүшәмбе – җомга 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр.

12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр – төшке аш вакыты.

Шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

Хакимиятләр бинасына керү ирекле.

5. Шәһәрнең районнар хакимиятләренең белешмә телефоннары:

Комсомол районы – 70-45-46.

Үзәк районы – 38-21-83.

Автозавод районы – 56-50-71.

6. «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: www.nabchelny.ru.

7. Муниципаль хезмәт турындагы мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, районнар хакимияте биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре ярдәмендә:

«Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтында: www.nabchelny.ru;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

3) районнар хакимиятендә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон буенча);

4) районнар хакимиятендә язмача мөрәҗәгать иткәндә.

8. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, ст. 3822);

2) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, ст. 4179);

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы) (Челнинские известия, 10.12.2005, №№235-237, 30.12.2005, №№249-250);

4) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 17 апрелендәге 30/18 нче карары (алга таба – Шәһәр Советының 30/18 нче карары) («Челнинские известия», №30, 23.04.2014);

5) Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

6) Башкарма комитетның 2007 елның 16 июлендәге 754 нче боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре).

## II бүлек. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 9. Муниципаль хезмәтнең исеме | Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирү | Шәһәр Советының 30/18 нче карары |

| | | |
|---|---|---|
| 10. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органының исеме | Районнар хакимияте йөзендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | шәһәр Уставының 41 маддәсендәге 9 бүлекнең 12 пункты |
| 11. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә бирелгән таныклык.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат. | Әлеге административ регламент белән билгеләнде |
| 12. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | 30 көн | Эш регламентының III өлеше 1 бүлегенең 1, 12 пунктындагы 2 абзацы |
| 13. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирү турында гариза;<br>2) территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклык бирүгә бәйле мәсьәләләрне караганда территориаль иҗтимагый үзидарә исеменнән эш йөртүгә вәкаләтле вәкилнең шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;<br>3) территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе таныклыгын бирүгә бәйле территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенең хокукын (вәкаләтләрен) раслаучы документ күчермәсе;<br>4) территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенең 3x4 үлчәмле 2 фотосурәте | Исемлек әлеге административ регламент белән билгеләнде |
| 14. Муниципаль хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый | каралмаган | |

| | | |
|---|---|---|
| актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | | |
| 15. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килешенү таләп ителә торган Башкарма комитет структур бүлекчәләренең исемлеге | шәһәрнең район хакимияте | Эш регламентының III өлеше 5 бүлегенең 5.2 пункты |
| 16. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) тиешле булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру;<br>3) гаризада һәм аңа теркәлгән документларда алдан килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлегенә төшенергә мөмкинлек бирми торган җитди бозулар;<br>4) документларны тиешле булмаган органга тапшыру | Әлеге административ регламент белән билгеләнде |
| 17. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тапшырылган документларның әлеге административ регламентның 12 пунктында күрсәтелгән | Әлеге административ регламент белән билгеләнде |

| | | |
|---|---|---|
| | документлар исемлегенә туры килмәве тора | |
| 18. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы һәм башка түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 19. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 20. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | 15 минут | |
| 21. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | 15 минут | |
| 22. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору | Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган район хакимиятләре түбәндәге адреслар буенча урнашкан: | «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә |

| | | |
|---|---|---|
| урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Комсомол районы – ГЭС поселогы, 8/7 йорт, 6 кабинет,<br>Үзәк районы – Яңа шәһәр, 3/08 йорт, 101 кабинет,<br>Автозавод районы – Яңа шәһәр, 49/09 йорт, 215 кабинет.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу, аның чикләрендә хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикле инвалидларны да истә тотып. | инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге<br>419-ФЗ санлы Федераль закон |
| 23. Муниципаль хезмәттән файдалана алу мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлегенең саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәтне муниципаль хезмәтләр | Муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлегенең күрсәткечләре:<br>1) муниципаль хезмәт турында мәгълүмат Интернет челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырыла;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы – 30 көн;<br>3) муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә. | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүче күпфункцияле үзәктә алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатының күрсәткечләре:<br>1) гариза бирүчеләрнең шикаятьләре булмау;<br>2) күрсәтелә торган муниципаль хезмәтнең әлеге административ регламент таләпләренә туры килүе;<br>3) муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын үтәү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитетның вазыйфаи затлары белән үзара хезмәттәшлек саны – 4 (теркәүне исәпкә алмыйча), аларның дәвамлылыгы – һәрберсе 15 минуттан артык түгел.<br>Күпфункцияле үзәкләрдә муниципаль хезмәт күрсәтелми.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат әлеге административ регламентның 3 пунктында күрсәтелгән телефоннар буенча алынырга мөмкин | |
| 24. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелми | |

## III бүлек. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре

25. Гариза бирүче яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән зат шәхсән яки телефон аша муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган район хакимиятенә мөрәҗәгать итә.

Район хакимияте белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документлар составы, формасы һәм эчтәлеге буенча.

Әлеге пункт беләнбилгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, шул исәптән тапшырылган документлар составы, формасы һәм эчтәлеге буенча.

26. Гариза бирүче шәхсән яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән зат, әлеге административ регламентның 13 пунктында каралган документларны теркәп, муниципаль хезмәт күрсәтү турында район хакимиятенә гариза бирә.

Район хакимияте белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

2) документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры һәм теркәлгән документлар исемлеге күрсәтелгән гариза күчермәсен гариза бирүчегә тапшыру.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.

27. Район хакимияте белгече кабул ителгән һәм теркәлгән гаризаны һәм документларны карап тикшерү өчен район хакимияте Башлыгы урынбасары, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү, территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү (территорияләр советларын үстерү буенча) бүлеге башлыгына (алга таба – хакимият Башлыгы урынбасары) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза һәм документлар хакимият Башлыгы урынбасарына җибәрелде.

28. Хакимият Башлыгы урынбасары гариза һәм документларны карап тикшерә, аларны Яр Чаллы шәһәренең торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү, территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү (территорияләр советларын үстерү буенча) бүлеге белгеченә (алга таба – ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгече) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

29. ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгече:

1) норматив хокукый база таләпләрен исәпкә алып гариза һәм документларны карый;

2) әзерли:

- әлеге административ регламентның 17 пунктында каралган нигезләр буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат;

- билгеләнгән үрнәктәге таныклык бланкына территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенең фамилиясен, исемен, атасының исемен кертә, территориаль иҗтимагый үзидарә органы исемен, таныклыкның гамәлдә булу срогын күрсәтә һәм фотосурәт ябыштыра;

3) әлеге пунктның 2 пунктчасында каралган документларны килешенү өчен хакимият Башлыгы урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенү өчен хакимият Башлыгы урынбасарына җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат яисә билгеләнгән тәртиптә тутырылган территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе таныклыгы бланкы.

30. Хакимият Башлыгы урынбасары әлеге административ регламентның 29 пунктының 2 пунктчасында каралган документларны карап тикшерә, килешенә һәм аларны килешенү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат яисә билгеләнгән тәртиптә тутырылган территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе таныклыгы бланкы.

31. Хакимият Башлыгы әлеге административ регламентның 29 пунктының 2 пунктчасында каралган документларны карап тикшерә һәм түбәндәге карарны кабул итә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны имзаларга һәм ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгеченә җибәрергә;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе таныклыгы бланкын имзаларга, тиешле район хакимияте мөһере белән таныкларга һәм ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгеченә җибәрергә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм ТКХ һәм Б, ТИҮүстерү бүлеге белгеченә җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат яисә билгеләнгән тәртиптә тутырылган территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе таныклыгы бланкы.

32. ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгече:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны терки һәм гариза бирүчегә җибәрә;

2) имзаланган таныклыкны таныклыкларны исәпкә алу һәм бирү кенәгәсендә терки;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе таныклыгы бланкында исәп номерын куя;

4) таныклык бланкының эчке як уң өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенең шәхси имзасын куйдыра һәм территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклыкны шәхсән бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм гариза бирүчегә җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат яисә теркәлгән һәм территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә бирелгән территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе таныклыгы.

33. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге административ регламентка № 2 кушымтада каралган.

## IV бүлек. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формасы

34. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүне, шикаятьләрне карап тикшерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерү үткәрүне, район хакмиятләренең вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) агымдагы контроль:

муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларына экспертиза үткәрү. Экспертизаларның нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

- билгеләнгән тәртиптә эш алып баруны тикшерү;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

35. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы район хакимияте Башлыгы урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

36. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә эш итүләргә контрольне гамәлгә ашыру һәм карарлар кабул итү максатларында хакимият Башлыгына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

37. Контроль тикшерүләр планлы (район хакимиятләренең ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр дә каралырга мөмкин (комплекслы тикшерүләр) яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

38. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

39. Гариза бирүчеләр тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту әлеге Административ регламентта каралган мәгълүматны алу юлы белән, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәткәндә карар кабул итүче вазыйфаи затның эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## V бүлек. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

40. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар районнар хакимиятенең муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләрнең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәк белгечләре буенча – күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.

41. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, 210-ФЗ санлы Федераль законның 15.1. маддәсендә күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан

Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

42. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), КФҮнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

43. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, күпфункцияле үзәкнең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

44. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, гариза бирүче – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

45. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

46. Шикаять гариза бирүче яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

47. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актларында түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

48. Әлеге Регламентның 47 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон төрдә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

49. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.

50. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән

вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

51. Судка шикаять бирү

Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Территориаль иҗтимагый үзидарә
рәисенә таныклык бирү буенча
административ регламентка
1 нче кушымта (белешмә)

Территориаль иҗтимагый үзидарә
рәисенә таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен
җаваплы вазыйфаи затларның
реквизитлары

Автозавод районы хакимияте

| Т/с | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 1. | Хакимият Башлыгы урынбасары | | |
| 2. | ТКХ һәм Т, ТИҮ үстерү бүлеге белгече | | avtoispolcom@mail.ru |

Үзәк районы хакимияте

| Т/с | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 1. | Хакимият Башлыгы урынбасары | | |
| 2. | ТКХ һәм Т, ТИҮ үстерү бүлеге белгече | | ispolkom_cik@mail.ru |

Комсомол районы хакимияте

| Т/с | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 1. | Хакимият Башлыгы урынбасары | | |
| 2. | ТКХ һәм Т, ТИҮ үстерү бүлеге белгече | | ikkr@mail.ru |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

Территориаль иҗтимагый үзидарә
рәисенә таныклык бирү буенча
административ регламентка
2 нче кушымта

# ТЕРРИТОРИАЛЬ ИҖТИМАГЫЙ ҮЗИДАРӘ РӘИСЕНӘ ТАНЫКЛЫК БИРҮ БУЕНЧА МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮНЕҢ БЛОК-СХЕМАСЫ

Гариза бирүче

Әлеге административ регламентның 13 пунктында каралган документларны теркәп, район хакимиятенә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирә

→ Гариза һәм документлар

↓

Тиешле район хакимияте белгече:

Район хакимияте белгече гамәлгә ашыра:
1) гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;
2) документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры һәм теркәлгән документлар исемлеге күрсәтелгән гариза күчермәсен гариза бирүчегә тапшыруны

→ Кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар

↓

Район хакимияте белгече

Кабул ителгән һәм теркәлгән гаризаны һәм документларны карап тикшерү өчен хакимият Башлыгы урынбасарына җибәрә

→ Район хакимияте Башлыгы урынбасарына җибәрелгән гариза

↓

Хакимият Башлыгы урынбасары

Хакимият Башлыгы урынбасары гаризаны һәм документларны карап тикшерә, аларны ТКХ һәм Т, ТИҮ үстерү бүлеге белгеченә җибәрә

ТКХ һәм Т, ТИҮ үстерү бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар

ТКХ һәм Т, ТИҮ үстерү бүлеге белгече

ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгече:
1) норматив хокукый база таләпләрен исәпкә алып гаризаны һәм документларны карый;
2) әзерли:
- әлеге административ регламентның 14 пунктында каралган нигезләр буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат;
- билгеләнгән үрнәктәге таныклык бланкына территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенең фамилиясен, исемен, атасының исемен кертә, территориаль иҗтимагый үзидарә органы исемен, таныклыкның гамәлдә булу срогын күрсәтә күрсәтә һәм фотосурәт ябыштыра;
3) әлеге административ регламентның 29 пунктының 2 пунктчасында каралган документларны килешенү өчен хакимият Башлыгы урынбасарына җибәрә

Килешенү өчен хакимият Башлыгы урынбасарына җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат яисә билгеләнгән тәртиптә тутырылган таныклык бланкы

Район хакимияте башлыгы урынбасары

Хакимият Башлыгы урынбасары әлеге административ регламентның 29 пунктының 2 пунктчасында каралган документларны карап тикшерә, килешенә һәм аларны килешенү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрә

Килешенү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат яисә билгеләнгән тәртиптә тутырылган таныклык бланкы

Хакимият Башлыгы:

Әлеге административ регламентның 29 пунктының 2 пунктчасында каралган документларны карап тикшерә һәм түбәндәге карарны кабул итә:
1) таныклык бланкын имзаларга, тиешле район хакимияте мөһере белән таныкларга һәм ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгеченә җибәрергә;
2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны имзаларга һәм ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгеченә җибәрергә

Имзаланган һәм ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгеченә җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат яисә билгеләнгән тәртиптә тутырылган таныклык бланкы

ТКХ һәм Б, ТИҮ үстерү бүлеге белгече:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны терки һәм гариза бирүчегә җибәрә;
2) имзаланган таныклыкны таныклыкларны исәпкә алу һәм бирү кенәгәсендә терки;
3) территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе таныклыгы бланкында исәп номерын куя;
4) таныклык бланкының эчке як уң өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенең шәхси имзасын куйдыра һәм территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә таныклыкны бирә

→

Теркәлгән һәм гариза бирүчегә җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат яисә теркәлгән һәм территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенә бирелгән таныклык

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Г.К. Әхмәтова